ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы территориясендә физик һәм юридик затлар өчен цифрлы сумны этаплап гамәлгә кертү турында

Татарстан Республикасы территориясендә физик һәм юридик затлар өчен цифрлы сумны этаплап гамәлгә кертү турында Россия Федерациясе Үзәк банкының Идел-Нократ баш идарәсе бүлеге – Татарстан Республикасы буенча Милли банк идарәчесе М.Д. Шәрифуллин мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы территориясендә физик һәм юридик затлар өчен цифрлы сумны этаплап гамәлгә кертү турында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Россия Федерациясе Үзәк банкының Идел-Нократ баш идарәсе бүлеге – Татарстан Республикасы буенча Милли банкына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2.1. Цифрлы сум платформасы турында мәгълүмати материалларны Татарстан Республикасы Дәүләт Советына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

2.2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары вәкилләре өчен цифрлы сум белән эш итү мәсьәләләре буенча укыту семинарлары, шулай ук халыкны агарту һәм аның финанс грамоталылыгын арттыру максатларында вебинарлар һәм подкастлар оештырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

3.1. 2027 елның 1 июленнән Татарстан Республикасы бюджеты акчалары белән операцияләр башкарганда цифрлы сумнан файдалану мөмкинлеген тәэмин итәргә.

3.2. Дәүләт түләүләре һәм муниципаль түләүләр системасына цифрлы сумны гамәлгә кертү чаралары планын эшләргә.

3.3. Цифрлы сумны гамәлгә кертү мәсьәләләре буенча республика башкарма хакимият органнары эшен координацияләүне тәэмин итәргә.

4. «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Татарстан Республикасының профильле министрлыклары һәм банк секторы оешмалары ярдәмендә цифрлы сумнан файдалану мөмкинлекләре турында халыкка һәм бизнеска мәгълүмат бирүне дәвам итүне тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетына республика башкарма хакимиятнең тармак органнары белән берлектә Татарстан Республикасы банк секторы оешмалары һәм фәнни бергәлек белән хезмәттәшлектә цифрлы сум әйләнеше өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала торган законнарны камилләштерү максатларында хокук куллану практикасына мониторинг ясауны һәм норматив хокукый базаны анализлауны дәвам итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы — М.Г. Әхмәтов

Казан шәһәре
2026 елның 22 сентябре
№ 191-VII ДСП